**Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Иске Иштирәк авыл җирлегенең Ялтау торак пунктында гражданнар җыены карары**

2025елның 29 ноябре № 2

**Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Иске Иштирәк авыл җирлегенең Ялтау торак пунктында 2026 елда гражданнарга үзара салым кертү турында**

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары нигезендә, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы белән, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 22 ноябрендәге 909 номерлы карары белән расланган (25.11.2024 №1049 редакциясендә) Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына гражданнарның үзара салым акчаларын җәлеп итеп гамәлгә ашырыла торган җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибенең 2 пункты белән, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Иске Иштирәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 24.1 маддәсе белән, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Иске Иштирәк авыл җирлегенең Ялтау торак пункты гражданнар җыены КАРАР БИРДЕ:

1. 2026 елда Лениногорск муниципаль районы Иске Иштирәк авыл җирлегенең Иске Иштирәк торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, ветераннар һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашучылардан, мобилизацияләнгән гражданнардан, контракт хезмәте хәрбиләреннән, балачактан инвалидлардан, шулай ук I төркем инвалидлардан, көндезге бүлектә белем алучы студентлардан тыш, 1000,00 (Бер мең) сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Ялтау авылының Тынычлык урамындагы вак таш түшәмәсе).

3. Әлеге карарны түбәндәге адрес буенча урнашкан мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә: Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Иске Иштирәк ав., Мәктәп ур., 15 й.; Бәкеав., Таулы ур., 38 й.; Ялтау ав., Тынычлык ур., 27 йорт, Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (http://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru/) каббул ителгәннән соң 10 көн эчендә бастырып чыгарырга.

Лениногорск муниципаль районы
«Иске Иштирәк авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы Г.Р.Шәрәпова